КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 7 июль г.Казань № б-1509

Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларында өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның яшәү шартларын яхшырту һәм әлеге оешмаларда чиратны киметү (профилактикалау) максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларына урнаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексын (алга таба – Чаралар комплексы) расларга.

2. Чаралар комплексын гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:

тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча чикләрендә Чаралар комплексы чаралары үтәлешен тәэмин итәргә;

Чаралар комплексында аларны үтәү өчен билгеләнгән срокларда Чаралар комплексы чараларын үтәү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Чаралар комплексы үтәлеше турындагы гомумиләштерелгән мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А.Голикова тарафыннан 2023 елның 9 мартында расланган 2455п-П45 номерлы Социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларга урнаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексында билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 июль, б-1509 нчы
боерыгы белән расланды

2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларына урнаштыру өчен өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексы

| Т/с | Чараның исеме | Көтелә торган нәтиҗә | Җаваплы башкаручылар | Үтәү срогы | Документ төре |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| I. Социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларның эшли торган челтәре эшен камилләштерү чаралары | | | | | |
| 1.1. | Ел саен социаль хезмәт күрсәтелә торган оешмалар (алга таба – стационар оешмалар) биналарын капиталь ремонтлау программасын раслау | Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләрнең яшәү шартларын яхшырту | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы |
| 1.2. | Россия Федерациясе Хезмәт | Стационар формада социаль хезмәтләр күрсә- | Татарстан Республикасы Хезмәт, халык- | 2023 елның 1 октябренә кадәр | Россия Федерациясе Хезмәт һәм |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, аларның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» боерыгы нигезендә стационар оешмаларның кадрлар белән тәэмин ителешен, матди-техник базасын мониторинглауны гамәлгә ашыру һәм хезмәткәрләрнең штат санын арттыру турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү | телүчеләрнең яшәү шартларын яхшырту | ны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | социаль яклау министрлыгына доклад |
| 1.3. | Торак урыннар мәйданы белән тәэмин итү нормативларын бозып, стационар оешмаларда урнаштырылган социаль хезмәт күрсәтелүчеләр санын киметү | Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтелүчеләрнең яшәү шартларын яхшырту | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| II. Стационарны алыштыручы технологияләрне үстерү чаралары | | | | | |
| 2.1. | Стационар оешмаларга урнаштыру өчен гражданнарның чиратын, шул исәптән: гражданнарның яшь составын (хезмәткә сәләтле һәм хезмәткә яраксыз яшен); гражданнарны стационар формада социаль хезмәт күрсә- | Чиратны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар кабул итү буенча идарә карарларын кабул итү өчен аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | телүгә мохтаҗ дип тану өчен нигез булган хәлләрне (сәбәпләрне) мониторинглау (анализлау) | | | | |
| 2.2. | Стационар оешмаларда тәүлек буе даими яшәп, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелүче, социаль хезмәт күрсәтүнең башка формаларында, шул исәптән стационарны алмаштыра торган технологияләр ярдәмендә социаль хезмәтләр алырга әзер булучы гражданнар санын билгеләү | Стационар учреждениеләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең башка формаларында социаль хезмәтләр алырга әзер булган социаль хезмәт күрсәтелүчеләр санын билгеләү | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| 2.3. | Стационарны алмаштыра торган технологияләрне кулланышка кертү, шул исәптән: | | | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | |
| 2.3.1. | даими булышлык күрсәтеп торыла торган яшәү | Даими булышлык күрсәтеп торыла торган яшәүгә чыгару<br>2023 ел – 13 кеше;<br>2024 ел – 17 кеше;<br>2025 ел – 21 кеше | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| 2.3.2. | өлкән кеше өчен тәрбиягә алган гаилә | Социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган, хокукый сәләткә ия өлкән | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | яшьтәге гражданнар өчен тәрбиягә алган гаиләләр булдыру:<br>2023 ел – 33 кеше;<br>2024 ел – 34 кеше;<br>2025 ел – 35 кеше | | | |
| 2.4. | Стационарны алмаштыра торган технологияләрне кулланышка кертүнең иң яхшы төбәк практикаларын гомумиләштерү | Стационарны алмаштыра торган технологияләрне кулланышка кертү буенча иң яхшы төбәк практикалары буенча аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| 2.5. | Өйдә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга өйдә социаль хезмәт күрсәтүне киңәйтү чаралары (социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмага урнаштыруны профилактикалау максатларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күләменең җитәрлек булуын бәяләүне кертеп) | Өлкән гражданнарга һәм инвалидларга өйдә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| 2.6. | Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны өйдә карауны (озак вакыт карауны, сиделка хезмәтләрен кертеп) үстерү, дәүләткә карамаган социаль | Дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә хезмәтләр, сиделка хезмәтләре | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә субсидияләр бирү | күрсәтелә торган гражданнар санын арттыру | | 2025 ел | |
| 2.7. | Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүгә чиратта тору чорында өлкән гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү чаралары | Аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2023 елның 1 октябренә кадәр (арадаш), алга таба – ел саен 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |
| III. Социаль хезмәт күрсәтелә торган стационар оешмаларга гражданнарның чиратын киметү (профилактикалау) эшчәнлеген координацияләү | | | | | |
| 3.1. | 2023 – 2025 елларга стационар оешмаларга урнаштыру өчен өлкән гражданнарның һәм инвалидларның чиратын киметү (профилактикалау) буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту | Аналитик белешмә кәгазе | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | 2024 елның 1 мартына кадәр, 2025 ел | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына доклад |

____________________